МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.10.2020 г.Казань № 692

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 20 октябрендә 6891 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында к а р а р и т ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрне, расларга.
2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2020 елның 2 октябрендәге 692
номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 7 апрелендәге «Россиянең Мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга ел саен акчалата түләү билгеләү» турындагы 212 санлы боерыгындагы «Россиянең Мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга ел саен акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 7 июнендәге 317 санлы, 2016 елның 30 июнендәге 371 санлы, 2017 елның 8 июнендәге 349 санлы, 2018 елның 15 маендагы 365 санлы, 2018 елның 24 сентябрендәге 897 санлы, 2019 елның 7 маендагы 323 санлы, 2019 елның 19 августындагы 636 санлы, 2019 елның 13 ноябрендәге 1001 санлы, 2020 елның 31 мартындагы 215 санлы, 2020 елның 13 июлендәге 503 санлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән):

2 бүлекнең 2.14 пунктовнда:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 1 пунктчасында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгән объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен, инвалидларга түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектка һәм дәүләт хезмәте күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-нокталы шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын раслый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы "Йөртүче этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында" боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтен алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә башка төрле ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-нокталы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук теркәү бүлегендә аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

«Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 14 ст., 15 ст»;

2.15 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.15 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе»

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 25 апрелендәге 263 номерлы «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 13 июлендәге 503 санлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2 бүлектә:

2.8 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Алучының балигъ булган гаилә әгъзаларының, ата-аналарыннан (уллыкк алучылардан) яисә опекуннарыннан (попечительләрдәно) тыш, керемнәре булмау. Анда 18 яшькә кадәрге Инвалид баланы яисә балачактан I төркем инвалидны тәрбияләүче хезмәткә сәләтле булмаган затларга Тәртипнең 3.3 пунктында күрсәтелгән чорда айлык түләү билгеләнгән;" ;

2.14 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 1 пунктчасында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгән объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен, инвалидларга түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектка һәм дәүләт хезмәте күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-нокталы шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын раслый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы "Йөртүче этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында" боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтен алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә башка төрле ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-нокталы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук теркәү бүлегендә аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

«Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 14 ст., 15 ст»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче кушымта<br>айлык акчалата түләү билгеләү<br>буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең<br>административ регламентына 4 нче<br>кушымта

_____ санлы «Республика матди ярдәм күрсәтү
(компенсацион түләүләр)
үзәге» ДКУ
_______________________________________м
униципаль районындагы (шәһәр округында)(шәһәр округында) бүлегенә

Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага
айлык акчалата түләү билгеләү турында
гариза

Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага (балаларга) айлык акчалата түләү бирүегезне сорыйм:

| баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме | туган көне, ае һәм елы | туу турында акт язмасы реквизитлары |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

Гаилә составы, керемнәре турында мәгълүмат:

| № п/п | Фамилия, исеме (исемнәре), атасының исеме (булганда) | СНИЛС | Туганлык дәрәҗәсе [2] | Шәхесне раслаучы документ | Туган көне һәм урыны | гражданлык | Яшәү урыны (паспорт буенча/вакытлыча яшәү урыны) | Башка керемнәр турында мәгълүмат [3] | Никахны теркәү турында акт язмасы реквизитлары (саны, датасы һәм теркәгән орган исеме) - хатыны өчен |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1[1] | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

[1] Беренче юл белән мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр күрсәтелә.

[2] Түбәндәге әһәмиятләрнең берсе күрсәтелә: әнисе, әтисе, ире (хатыны), балигъ булмаган бала, опекун, попечитель.

[3]Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 31 мартындагы «3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру тәртибенә төп таләпләрне, әлеге айлык түләүне билгеләү өчен кирәкле документларның (белешмәләрнең) якынча исемлеген һәм аны билгеләү турында гаризаның типовой формасын раслау хакында» 384 санлы карары белән расланган айлык түләү билгеләү өчен кирәкле документларның (белешмәләрнең) якынча исемлеге белән каралмаган керемнәр төре һәм күләме күрсәтелә.

☐ Айлык түләүне кредит оешмасы аша түләвегезне сорыйм:

______________________________________________________________

| | |
|---|---|
| Кредит оешмасы исеме | |
| Кредит оешмасының БИКы | |
| Кредит оешмасының ИННы | |
| Кредит оешмасының КППсы | |
| Гариза бирүченең исәп-хисап саны | |

Дата 2020 елның "___"____________ гариза бирүченең имзасы________________».

3. Хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмет иткән һәм полициянең махсус исемнәре булган затларның, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәү системасы учреждениеләре һәм органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең федераль янгынга каршы хезмәте, Россия Федерациясае таможня органнары, Татарстан Республикасы Хезмәт , халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә индивидуаль торак йортларны ремонтлауга акчалар түләүне билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2012 елның 08 августындагы 643 номерлы боерыгы белән расланган туендыручыны югалткан Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе милли гвардия армиясендә хезмәт иткән һәм махсус исемнәре булган затларның гаилә әгъзаларына шәхси торак йортларны ремонтлауга акча түләүләрен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2014 ел № 311, 04.05.2016 ел № 230, 08.06.2017 ел № 348, 07.05.2018 № 347, 19.09.2018 ел №892, 23.04.2019 ел № 297, 13.11.2019 ел №1001, 25.03.2020 ел №193, 14.07.2020 ел №511 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) административ регламентында:

2 бүлекнең 2.14 пунктовнда:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 1 пунктчасында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгән объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен, инвалидларга түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектка һәм дәүләт хезмәте күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-ноктал шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын расый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы "Йөртүче этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында" боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт

хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтен алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә башка төрле ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-нокталы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук теркәү бүлегендә аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

«Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 14 ст., 15 ст»;